Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авылы торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 2

2022 елның 24 ноябре

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль "Юлсубино авыл җирлеге" составына керүче Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Ямаш торак пунктында урам утларын ремонтлау
2. Ямаш авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау
3. Ямаш авылында яшәүчеләргә су алу, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау
4. Ямаш авылында кышкы һәм җәйге юлларны карап тоту
5. Ямаш авыл торак пунктында коммуналь калдыклар өчен контейнер мәйданчыгы төзү һәм контейнерлар сатып алу

Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов